**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 10 ноябрь № 861

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Белем алучыларны Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән туклану белән тәэмин итү очраклары һәм тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2014 ел, 26 сентябрь, 682 нче карары белән расланган Белем алучыларны Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән туклану белән тәэмин итү очраклары һәм тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Белем алучыларны Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән туклану белән тәэмин итү очраклары һәм тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2014 ел, 26 сентябрь, 682 нче карары белән расланган Белем алучыларны Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән туклану белән тәэмин итү очраклары һәм тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

түбәндәге эчтәлекле 8 нче пункт өстәргә:

«8. Белем алучыларны Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән туклану белән тәэмин итү буенча социаль чаралар күрсәтүче белем бирү оешмалары, бу карарга таянып, Социаль хезмәт күрсәтүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасы аша әлеге социаль ярдәм чаралары күрсәтү турындагы мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм күләмдә һәм Социаль хезмәт күрсәтүнең бердәм дәүләт мәгълүмат

системасы операторы тарафыннан билгеләнгән формат нигезендә бирүне тәэмин итә.».

2. Бу карар 2018 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\861.docx